| Республика Татарстан<br>СОВЕТ АЛЕКСАНДРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | Татарстан Республикасы<br>САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛЕКСАНДРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07 » ноябрь 2023 ел. с.Александровка № 6

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яхшы-Каран авыл җирлегенең торак пунктында 2024 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы " Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

1. Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Яхшы-Каран авылы, Родниковая урамы, 2А йорт адресы буенча урнашкан Яхшы-Каран авыл клубы бинасында 2023 елның 17 ноябрендә 13.00 сәгатьтә Сарман муниципаль районы Яхшы-Каран авыл җирлегенең 2024 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яхшы-Каран авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 төркем инвалидларыннан, ялгыз яшәүче (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлардан, ашыгыч хәрби хезмәт, контракт буенча хәрби хезмәт, мобилизация буенча хәрби хезмәт узучылардан тыш 2024 елда үзара салым кертүгә 500 сум күләмендә килешәсезме?

1) тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау, Яхши-Каран торак пунктында урам яктырту җайланмасы (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам яктыртуга хезмәт күрсәтү);

2) Яхши-Каран торак пунктында кышкы вакытта җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү) ;

3) Яхши-Каран торак пунктында һәйкәлләрне ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышында катнашучыларның исемлекләре язылган истәлек тактасы урнаштыру, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
4) Яхши-Каран торак пунктында Өлкәннәр көнен үткәрү өчен бүләкләр сатып алу.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны Александровка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән Сарман муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга .http://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 7 көн эчендә.
4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлеге башлыгы И.Ф.Вафин